**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1430**
**02.03.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктның 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 2 мартындагы
1430 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» МУП
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф, сум, ӨКС тыш |
|---|---|---|---|
| 1. | Төтен, җылылык һәм янгын турында катнаш хәбәр итү җайланмасына хезмәт күрсәтү | данә | 7,48 |
| 2. | Янгын турында кулдан хәбәр итү җайланмасына хезмәт күрсәтү | данә | 7,43 |
| 3. | Кабул итү-контроль приборына хезмәт күрсәтү | данә | 43,39 |
| 4. | Индикация блогына хезмәт күрсәтү | данә | 36,20 |
| 5. | Реле блогына хезмәт күрсәтү | данә | 43,39 |
| 6. | Янгын турында тавыш, сөйләм аша хәбәр итү җайланмасына хезмәт күрсәтү | данә | 7,43 |
| 7. | Янгын турында яктылык аша, катнаш хәбәр итү җайланмасына хезмәт күрсәтү | данә | 7,57 |
| 8. | Идарә итү пультына хезмәт күрсәтү | данә | 72,16 |
| 9. | Резерв туендыру чыганагына хезмәт күрсәтү | данә | 21,82 |
| 10. | Аккумуляторга хезмәт күрсәтү | данә | 7,19 |
| 11. | Читтәге объект җайланмасына хезмәт күрсәтү | данә | 57,77 |
| 12. | Сигнализация шлейфына хезмәт күрсәтү | данә | 14,62 |
| 13. | Контроль-кабызу блогына хезмәт күрсәтү | данә | 36,20 |
| 14. | Янгын мониторингы системасы җиһазына хезмәт күрсәтү | данә | 72,16 |
| 15. | Күләмле хәбәр итү җайланмасына хезмәт күрсәтү | данә | 7,43 |
| 16. | Магнитлы датчикка хезмәт күрсәтү | данә | 7,43 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева